ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.02.2023 Баулы шәһәре №45

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Наем шартнамәләре буенча торак у бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 2021 елның 30 декабрендәге 243 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды турында» 2022 елның 14 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Наем шартнамәләре буенча торак у бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 2021 елның 30 декабрендәге 243 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 11 декабрендәге 880 номерлы карары белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Административ регламентта (карарга кушымта):

1 «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

түбәндәге эчтәлекле 1.6. пункт өстәргә:

«1.6. Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (проактив) режимда күрсәтү очраклары һәм тәртибе

Муниципаль хезмәт күрсәтүне алдан ук (проактив) режимда бирү каралмаган.»;

2 нче «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5.1. пунктындагы 1) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхесне таныклый торган документ (Россия Федерациясе гражданы паспорты йә шәхесне таныклый торган башка документ) яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарда, күпфункцияле үзәкләрдә, 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында»Федераль законның 14.1. статьяның 18 өлешендә каралган мәгълүмат технологияләреннән файдаланып идентификация һәм аутентификация юлы белән,;»;

2.6.1. пунктының 11 пунктчасында «Россия Федерациясе пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминләштерү фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров